# 9нчы сыйныфның рус төркемендә **БРТ** на әзерлек факультативы

Укытучы:Даутова Л.Р.

*Бөркөнне Фәрит әнисенең кушуы буенча кибеткә барган иде. Каракай да аңа иярде. Прилавка янында әйберләр караган чакта, бер хатын кинәт:*

*Урладылар, акчамны урладылар!- дип кычкырып җибәрде.*

*Фәрит озак уйлап тормады, әлеге хатынга:*

*Тизрәк кулъяулыгызны бирегез! – диде.*

*Хатын да: “Нигә?” – дип сорамады, сумкасыннан бизәкле кулъяулыгын алып, Фәриткә бирде.*

*Фәрит аны тиз генә Каракайга иснәтте дә:*

*Тиз эзлә! – диде.*

*Каракай сискәнеп китте. Әйтерсең ул кинәт йокысыннан уянды. Арт аякларына басып, башын як-якка боргалады, иснәде дә чабып китте. Йөзләгән аяклар арасыннан елан кебек кенә үтте. Фәрит аның артыннан чак-чак өлгерде. Каракай ишектән чыгарга теләгән яшь егетнең чалбарына ябышты. Фәрит каракка:*

*Ташла акчаны, ташла! – дип кычкырды.*

*Шунда таза гына бер кеше карак алдына килеп басты. Егет портмонены идәнгә ыргытты. Каракай аны, авызына кабып, Фәриткә китереп бирде.*

*Кибеттәге кешеләр авызларына су капкан кебек тордылар. Аларга бу хәл бик гаҗәп иде, әлбәттә. Кечкенә генә йорт эте каракны эләктерде бит!*

*Каракны тотып алдылар. Акчаны хуҗасына бирделәр. Ул хәтта бераз аптырап та калды. Әле хәзер генә кайгы иде – инде шатлык! (Нәби Дәүлидән)*

1.Фәрит әнисе кушуы буенча кая бара?
2.Прилавка янында нинди хәл була?
3.Каракай каракны ничек эзләп таба?
4.Карак үзен ничек тота?

- А7.  **Фәрит кибеткә бармады.**
- 1)текстка туры килә  2) текстка туры килми  3) текстта әйтелми
- А8. **Малайның Каракай исемле эте бар.**
- 1)текстка туры килә  2) текстка туры килми  3) текстта әйтелми
- А9. **Каракай карак артыннан чапты.**
- 1)текстка туры килә  2) текстка туры килми  3) текстта әйтелми
- А10. **Каракай Фәритләрдә күптән яши.**
- 1)текстка туры килә  2) текстка туры килми  3) текстта әйтелми
- А11. **Бер хатынның акчасын урлаганнар.**
- 1)текстка туры килә  2) текстка туры килми  3) текстта әйтелми
- А12. **Егет портмонены Фәриткә китереп бирә.**
- 1)текстка туры килә  2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми
- А13. **Каракай – зур эт**.
- 1)текстка туры килә  2) текстка туры килми  3) текстта әйтелми
- А14. **Хатын Фәриткә рәхмәт әйтә.**
- 1)текстка туры килә  2) текстка туры килми  3) текстта әйтелми

| Текстлар | А | Ә | Б | В | Г | Д | Е |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| Исемнәр | 1 | 4 | 2 | 3 | 5 | 8 | 6 |

1.Рөстәмнең эше күп булды.
2.Малай ишегалды себерә башлады.
3.Иртән җырлаган кешенең бәхете булмый.
4.Малайны әбисе мактады.
5.Кунаклар күп күчтәнәчләр алып килделәр.
6.Күрше әбиләр Рөстәмне мактадылар.
7.Кибеткә барасым килә.
8.Әбинең сүзләрен ничек аңларга.

# Исемнәрнең килеш белән төрләнеше

| | |
|---|---|
| Баш килеш | кем? нәрсә? |
| Иялек килеше | кемнең? нәрсәнең? |
| Юнәлеш килеше | кемгә ? нәрсәгә? кая? |
| Төшем килеше | кемне? нәрсәне? |
| Чыгыш килеше | кемнән? нәрсәдән? кайдан? |
| Урын –вакыт килеше | кемдә? нәрсәдә? кайда? кайчан? |

- 
- **Б. к.** имтихан бирем
**И. к.** имтихан бирем
**Ю. к.** имтихан бирем
**Т. к.** имтихан бирем
**Ч. к.** имтихан бирем
**У–в. к.** имтихан бирем

1. Алсу имтихан________ тырышып әзерләнде.
2. Артем имтихан________ шатланып кайтты.
3. Имтихан______ биремнәре авыр иде.
4. Мин татар теленнән   имтихан бирдем.
5. Имтихан________    бар белгәнеңне күрсәтергә кирәк.
6. Коля татар теленнән имтихан______ уңышлы тапшырды.

Кичә без татар **театрына** бардык. (театр)

Анда Кәрим Тинчуринның “Зәңгәр шәл”**әсәрен** карадык. (әсәр)

**Театрга** кешеләр күп килгән иде. (театр)

Артистларның уены **барыбызга** да бик ошады. (барыбыз)

Тамашачылар аларны көчле **алкышларга** күмделәр. (алкыш)

Ике сәгать вакыт бик тиз **үтте.** (үтәргә)

Спектакль тәмамланганда, барыбызның да **кәефе** яхшы иде. (кәеф)

Өйгә **кайтканда** , без артисларның оста уены турында сөйләштек. (кайтырга)

Сыйныфыбызда егерме дүрт укучы бар, ә **укытучыбызның** исеме - Алсу Дамировна. (укы)

Без бик дус һәм **күңелле** яшибез. (күңел)

**Төрле** экскурсияләргә, театрларга бергә йөрергә яратабыз, кичәләр үткәрәбез. (төр)

Сыйныфташлар белән **татарча** , русча, инглизчә фильмнар карарга яратабыз. (татар)

Сыйныф җитәкчебез безне **фәнни** эшләр язарга өйрәтә. (фән)

Без бигрәк тә татар халкы тарихы белән **кызыксынабыз** бу турыда күп китаплар укыйбыз. (кызык)

Безнең бер **сыйныфташыбыз** тарихтан олимпиадада җиңүче булды. (сыйныф)

# 9 нчы сыйныф укучыларына БРТ эшендә хат язу алгоритмы

1.**Биремне игътибар белән укыгыз.** Терәк хаттагы сорауларны ачыклагыз.

2.**Хатның башлам өлешен языгыз**. Башлам өлешендә исәнләшү була, хатны язучының исеме әйтелә. Хәлләр сорала. Алынган хат өчен рәхмәт белдерелә.

3.**Терәк хаттагы мәгълүматка фикерегезне белдерегез.** Андагы мәгълүматны сылтама ( приписание) буларак файдаланыгыз.

4.**Терәк хаттагы сорауларга җавап языгыз**. Җавабыгызда шулай ук терәк хаттагы гыйбарәләрне (выражение) куллана аласыз.

5.**Хатыгызны йомгаклагыз**. Йомгак өлешендә үз сорауларыгызны да бирә аласыз. Саубуллашырга, җавап хаты көтүегезне белдерергә онытмагыз. Шулай ук хатны язучының исемен(үз исемегезне ) һәм хат язылу көнен күрсәтергә кирәк.

**Терәк сүзләр һәм сүзтезмәләр:** әбием шатлана, төрле эшләр, савыт –саба, яшелчә, өй җыештыру.

# Уңышлар сезгә!!!